Республикакүләм фәнни - гамәли конференция

**«Фәнгә адымнар»**

Эзләнү эше

# Тема: Математика – серләр дөньясы

*Автор:*

Фазылҗанова Рамилә,

Балтач муниципаль районы

МБГБМ «Түнтәр урта гомуми

белем мәктәбе», 7 класс

*Җитәкчеләре:*

югары квалификацион категорияле

математика укытучылары

Гарифуллина Раиля Рифкатовна,

Гарифуллин Расиль Габдуллович

**Максат**: мәктәптә укучыларның математика фәне белән кысыксыну һәм үзләштерү дәрәҗәсен ачыкларга һәм әлеге күрсәткечләрне үстерү өстендә эшләргә.

**Бурычлар:**

- мәктәптә укучыларның математика фәне белән кысыксыну һәм үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау ;
- үткәрелгән анкета һәм мониторингларны анализлау;
- теоретик мәгълүмат тупларга һәм өйрәнү;
- математика өйрәнүне кызыклы итү өчен күнегүләр туплау;
- тупланган күнегүләр ярдәмендә укучыларга мастер-класс күрсәтү, фәнгә кызыксынуларын арттыру;
- сыйныфларда элеге юнәлештәге эшчәнлекне укучылар үзидарәсе белән берлектә дәвам итү;
- башкарылган эшкә анализ һәм нәтиҗә ясау;
- кабинет лабораториясе өчен электрон уку ярдемлеге (учебное пособие) ясау.


**Эзләнү объекты:** Түнтәр урта гомуми белем мәктәбенең 5-7 нче сыйныф укучылары.

Математика үзләштерүдә, нәкъ тормыштагы кебек, чишеп булмаслык каршылыклар юк. Бары тик аның белән кызыксынырга һәм даими шөгыльләнергә генә кирәк.

**Гипотеза:** Математика –гаять катлаулы да , кызыклы да фән. Югары сыйфатка ирешү нәтиҗәсе – өстенлекле ысулны дөрес сайлауда.

# Мәктәптә укучыларның математика фәне белән кысыксыну һәм үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау нәтиҗәләре.

## Математика - кызыклы фән:



Эзләнү эшемне нәтиҗәле итү максатыннан **“Фикерләү тренеры”, “Тизлек тренеры”** һәм **“Хәтер тренеры”** рольләрен башкардым.

**Эзләнү эшенең практик эшчәнлегендә кайбер кагыйдәләр формалаштыру бурычы да килеп чыкты:**

- **Мин кемгә мөрәҗәгать итсәм, димәк ул 3 секунд эчендә җавап бирергә тиеш;**
- **Мин кулымны югары күтәрәм икән, димәк игътибарлы булуыгыз сорала;**
- **Мин кулларымны алга сузам икән, димәк сез кул чабарга әзер булырга тиеш.**

## Математика – кызыклы фән.


### Практик эшчәнлек:


# 1. Фикерләү тренеры эшчәнлеге

2018 – Эт елы – тынычлык , муллык , уңышлар

һәм сәламәтлек тели








1. Сәяхәткә ничә дус килгән?

   (4 дус-кашык, тәлинкә)
2. Сәяхәткә нәрсә белән килгәннәр?

   (көймә, бойдарка белән)
3. Алар кая урнашканнар?


   (авыл тирәсенә, чөнки тавык йөри)
4. Алар кайчанрак килеп урнашканнар?

   (бер-ничә көн элек, палатка почмагында үрмәкүч челтәре күренә)



**10 төп роза гөлен 5 рәткә 4 әр роза булырлык итеп утыртып бу**

(Җавапны нигезләргә)





# 2. Хәтер тренеры эшчәнлеге:

**Мин әйткән саннар эзлеклелеген дәвам итеп өч сан әйтегез:**

**1. 3, 5, .....**

**(7, 9, 11)**

**2. 11, 14, 17, .....**

**(20, 23, 26)**

**3. 512, 256, 128, ...**

**(64, 32, 16)**

## 3. “Математиканы уйнап – көлеп” .

# 5 кә бүлә беләсезме?

$$190 : 5 = 38$$

$$\begin{array}{r} \times\ 190 \\ 2 \\ \hline 38{,}0 \end{array}$$

# Санны 11 гә тапкырлау:

**1.**

$$\begin{array}{r} 23 \\ \times\ 11 \\ \hline 253 \end{array}$$

**2.**

$$\begin{array}{r} 57 \\ \times\ 11 \\ \hline 7 \end{array}$$


$5 + 7 = 12$

$5 + \quad = 6$

Тапкырлау таблицасын ятлый алмый азапланучы укучылар өчен **кытай** алымы:


**1.**

**2 · 3 =**




**2.**

$12 \cdot 13 = 156$



**3.**

**16 · 14 = ?**



# Таяну ноктасы ярдәмендә тапкырлау:

**1.**

$3 \cdot 2$

$+$

$13 \cdot 12 =$

$10 \cdot 15 + 6 = 156$

**2.** $18 \cdot 23 = 414$

$-2 \cdot 3 = -6$

$18 \cdot 23$

$20 \cdot 21 + (-6) = 414$

**3.** $97 \cdot 104 = 10088$

$-3 \cdot 4 = -12$

$97 \cdot 104$

$100 \cdot 101 + (-12) = 10088$

## Икеурынлы 5 кә тәмамланган саннарны квадратка күтәрү:

Дистә цифры һәм аңа берне кушу нәтиҗсендәге цифр тапкырчыгышы азагына 25 не язарга кирәк.

$$25^2 = (2 \cdot 3)25 = 625;$$

$$45^2 = (4 \cdot 5)25 = 2025.$$

$$75^2 = (7 \cdot 8)25 = 5625.$$

## 50 дән зуррак икеурынлы санны квадратка күтәрү:

n - бирелгән сан,

1) $a=n-50$ ;


2) $n^2=100 \cdot (n-25)+a^2$

**Мисал:** $n=64$,

1) $a=64-50=14$ ;

**2)$64^2=100\cdot(64-25)+14^2=100\cdot 39+196=$**

**$=3900+196=4096$**



AB=13 см
D
37° ⇔ 3,7 см
OD=AO=OB
M
K
A
O
B
N
∠KOB = 37°

**Йомгаклау өлеше.**

Мин эзләнү эше үткәргән вакытта берсеннән-берсе кызыклы исәпләү алымнарын өйрәтеп җайлы исәпләү күнекмәләрен формалаштырдым һәм математика дәресләрендә кыен хәлләрдән чыгу юлларын күрсәттем. Укучыларда фән белән кызыксыну артты, үзләре дә кызыклы алымнар эзли башладылар. Логика, тизлек һәм хәтер тренерлары вазыйфаларын башкару теләге уянды. Математика фәне үрләрен яулауда икенче сулыш ачылды. Мин үземнең башкарган эшемнән бик канәгать. 5-7 нче сыйныф укучылары арасында дәрестән тыш эшчәнлектә без нәкъ менә шушы юнәлештә эш алып барабыз. Мин үземнең башкарган эшемне Flip-PDF форматында электрон методик пособие итеп ясап математика кабинеты лабораториясенә тапшырдым. Минем эшем киләчәк укучылар өчен дә файда китерер дип ышанам. Эшемне төгәлләгәндә мин “Математика –гаять катлаулы да , кызыклы да фән. Югары сыйфатка ирешү нәтиҗәсе – өстенлекле ысулны дөрес сайлауда” дигән гипотезам хаклыгына инандым. Шулай итеп гипотеза дәлилләнде. Без интернет чыганаклардан яңадан-яңа кызыклы алымнар табабыз һәм аны дәрестән тыш эшчәнлектә анализлыйбыз. Математика – серләр дөньясы!

# Соңгы сорашулар нәтиҗәсе

## Математика -  кызыклы фән




Электрон ярдәмлек